**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 июнь № 441

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында 2016 ел, 17 март, 147 нче карары белән расланган «2016 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында 2016 ел, 17 март, 147 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 31 март, 182 нче, 2016 ел, 8 апрель, 209 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2016 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында «Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлында «Татарстан Республикасы предприятиеләрендә эшләүчеләр санында эштән чыгу куркынычы булган хезмәткәрләр саны өлеше 1,7 проценттан артмый» сүзләрен «эштән чыгу куркынычы булган хезмәткәрләр саны 27 000 кешедән артмый» сүзләренә алмаштырырга;

Программаның «II. Программаның төп максатлары, бурычлары, көтелгән

соңгы төп нәтиҗәләр тасвирламасы, аны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары» бүлегенең сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программа чараларында катнашучыларның гомуми саны 12 094кеше.»;

Программаның V бүлегенең тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эштән чыгу куркынычы булган хезмәткәрләр саны 27 000 кешедән артмый.»;

Программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков